СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

10 октябрь, 1997 ел. ЖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 114 (8126) | Бәясе билгеләнгәнчә


### 1 - 10 октябрь: өлкәннәр декадасы

## Игътибар һәм кайгырту белән

**Районда дәвам иткән өлкәннәр көне ветераннарыбызга яңадан яңа игътибар билгеләре белән тулылана бара. Шундый игътибарга күңелләре булган өлкәннәр редакциягә хатлар язалар, телефоннан шалтыраталар. Юкса, кеше күңелен табарга күп тә кирәкми икән!**

Пенсионерлар үтенече буенча безгә Л.В.Поливанова менә нәрсәләр яза: «40 бабай һәм әби исеменнән МПП җитәкчелегенә рәхмәт белдерәсебез килә. Һәр елны халыкара өлкәннәр көнендә алар безгә чын мәгънәсендә бәйрәм ясыйлар: бай өстәлләр әзерлиләр, бүләкләр тапшыралар. Быел да шулай булды. Рәхмәт аларга!».

Бу көнне Н. Октябрь элеваторының 120ләп ветераны да бергә үткәрделәр: әүвәл клубта аларның хәл - әхвәлләрен сораштылар, аннан ашханәгә табын артына чакырдылар, азык - төлек пакетлары әзерләделәр. Бу традицияне биредә онытмыйлар.

«Бәйрәм көнне,- дип язалар А.Сударева, Н.Созонова һәм А.Любецкая,- «Кыңгырау» балалар яслесе коллективына, шәһәр Советы һәм район мәгариф бүлегенә чын бәйрәм кичәсе үткәрүләре өчен рәхмәт белдерәсе килә. Һәммәгезгә исәнлек, уңышлар һәм бәхет телибез».

## БЕР АТНАДА ЧИСТАРТЫЛА

Норлатта химчистка цехы эшләмәгәнгә инде бер елдан артык вакыт үтте. Шәһәр һәм авыл халкы аңа һәрвакыт мохтаҗлык кичерде. Анда өс һәм эш киемнәрен, юрган, плед һәм башка бик күп әйберләрне чистартырга алып, хуҗабикәләрне бик күп мәшәкатьтән арындыра иделәр. Бүген аларны куанычлы яңалык көтә: 10 нчы октябрьдән химчистка цехы яңадан эшли башлый. Алдагы фаразларга каршы, прейскурант биредә үзгәрмәде һәм бәяләр дә чагыштырмача түбән. Бу төр хезмәт күрсәтү бинасының адресы элеккечә калды: Гыйматдинов урамы, «Надежда» дәүләт предприятиесе административ бинасы.



Кайчан-кайчан,ә урак чорында шоферлар өчен эш кызу була. Бер карыйсың, басу белән ындыр табагы арасында ашлык ташыйлар алар,икенче карыйсың-элеваторга юл тоткан булалар. Инис та шулай бер караңгыдан икенчесенә кадәр эш белән мәшгуль булды быелгы уракта.

Хәер, алдагы бер-ике айда да киеренкелек йомшарыр төсле түгел әле: шикәр чөгендере казыта башлагач та Инисның «КамАЗ»ы өчен эш күп булачак.Уңган шофер икенче уракта да сынатмаска ниятли.

**Рәсемдә:»Үрнәк» КХАсы шоферы И.Хәйдәрҗанов.**
**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## ЧЫН КҮҢЕЛДӘН КОТЛАУ

***Авыл эшчәненең мәшәкате кимеми. Шикәр чөгендерен вакытында казып алып һәм чистартып хәзерләүләр пунктына озатасы, туңга сөрәсе бар - болар бүгенге көннең беренче чираттагы бурычлары. Механизаторлар Николай Иванович Абрамов (шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгы), Наил Камил улы Гыймадиев («Кондырча» КХАсы), Фәнил Җәмил улы Нуретдинов («Әлмәт»), Гали Гариф улы Әхмәтшин («Киекле») һәм Вәгыйзь Гаяз улы Җирҗизов («Дуслык» КХАсы) үзләренең бурычларын уңышлы үтиләр. Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин әлеге уңганнарга котлау хатлары җибәреп, аларга җылы теләкләрен ирештерде. «Сез киләчәктә дә хезмәттә яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен көчегезне, осталыгыгызны һәм максатчанлыгыгызны кызганмассыз дип ышанам», диелә аларда.***

***Бу көннәрдә районның тагын унлаган комбайнчысы, шоферы һәм механизаторы шундый котлау хатлары алдылар.***

## Ышанычлы кеше ул

«Чирмешән» хуҗалыгының беренче бригадасында кырчылык тармагында эшләрнең барышын Хәниф Нурмөхәммәтовтан да яхшырак белүче юктыр.Учетчы хезмәтен башкара ул.Иртә яздан кара көзгәчә кырларны аркылыга буйга иңли.Һәр эшнең исәбен төгәл алып бара.Хуҗалыкның техника куркынычсызлыгы буенча җаваплы кешесе дә ул, контроль-ривизия комиссиясен дә җитәкли, кыскасы хуҗалыктагы эшләрнең үзәгендә кайный.Гаиләсендә дә тәртип.Хатыны Сәрфия апа белән дүрт бала үстерделәр.Илһамия белән Илшат Түбән Кама шәһәрендә яшәсәләр,Ринатлары гаиләсе белән үзләре янында (Ринат хуҗалыкта шофер,киленнәре Рәзинә-китапханәче.Ике кыз үстерәләр).Кече кызлары мәктәптә белем ала.Сәрфия апа терлекчелектә эшли.Дөнья ягтысы күрүдән мәхрүм әниләре Хәкимә әбине тәрбиялиләр.

Әнә шундый эшчән,бердәм гаилә алар.Ә Хәниф абый гаилә корабын кулында нык тота.

**Җ.ШАКИРОВ.**

## Хөрмәтле дуслар!

**1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу бара. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

**Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.**

# Икенче уракта да исәп кирәк

**Саннарның беренче баганасы - район хуҗалыкларында 8 октябрьгә шикәр чөгендере казу, икенчесе - 7 октябрьгә аны хәзерләү турында мәгълүматлар (планга карата процентларда).**

| | | |
|---|---|---|
| «Дуслык» | 100 | 44 |
| «Кондырча» | 91 | 48 |
| «Төрнәс» | 88 | 69 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 70 | 68 |
| «Якты Күл» | 70 | 24 |
| «Агрохимсервис» ярд. хуҗ. | 64 | 20 |
| «Татарстан» | 62 | 22 |
| Кузнецов исем. | 61 | 42 |
| «Заветы Ильича» | 60 | 37 |
| «Киекле» | 60 | 16 |
| «1 нче Май» | 57 | 25 |
| «Алга» | 56 | 11 |
| «Рассвет» | 55 | 25 |
| «Игенче» | 53 | 11 |
| Муса Җәлил исем. | 53 | 8 |
| «Әлмәт» | 50 | 19 |
| Мичурин исем. | 49 | 17 |
| Хафизов исем. | 47 | 36 |
| Сөт - май комбинаты ярд. хуҗ. | 46 | -- |
| «Родина» | 41 | 24 |
| «Чирмешән» | 41 | 16 |
| «Заря» | 37 | 9 |
| Синдряков исем. | 33 | 8 |
| «Таң» | 33 | 3 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 30? | 5 |
| «Комбайн» | 28 | 12 |
| «Үрнәк» | 24 | 4 |
| «40 лет Победы» | 20 | -- |
| МСО ярд. хуҗ. | 11 | -- |
| **Район буенча.** | **50** | **22** |

Шикәр чөгендеренең яртысы казып алынган шартларда әлегә аның заводка 25 мең тоннадан артыграк кына китерелүе борчу уята. Дөрес, ай башында тәүлек буе койган яңгыр чөгендерчеләрнең эшенә нык тоткарлык ясады: 3 - 4 октябрьләрдә шикәр заводына санаулы машиналар гына чимал китерде һәм чөгендер тапшыру 5 октябрьдә генә ишәеп китте. Ул көнне 1700 тоннадан артыграк чимал керсә, икенче көнне бу сан 2100 тоннадан күбрәк булды. Дөрес, бу ике көндә ташылган чөгендернең зур өлеше нигездә өч - Хафизов исемендәге, «Кондырча», Кузнецов исемендәге хуҗалыклар, шулай ук заводның үз ярдәмче хуҗалыгыннан килде. Әйтик, хафизовлылар бишесендә 54, алтысы көнне 80 йөк чөгендер китерделәр. «Кондырча»дан ике көндә кырыгар йөк чимал килде. Чимал тапшыру бераз сүрелеп торган «Киекле» хуҗалыгыннан да 6 октябрьдә 227 тонна чөгендер кабул ителде, «Игенче», «Чирмешән» хуҗалыклары да темпны арттыра төштеләр.

Әмма мәгълүматлар чөгендер әзерләүнең барлык хуҗалыкларда да бердәй бармавын бик ачык күрсәтә. Әйтик, 6 октябрьдә «Агрохимсервис», нефтебаза ярдәмче хуҗалыкларыннан бер - ике генә машина чөгендер озатып калдылар. Хафизов исемендәге хуҗалыкның машиналары көнгә бишәр - алтышар рейс ясавын күпләр аларның кырлары заводка якын булудан гына күрергә мөмкиннәр. Әмма, безгә калса, монда басуда озатыр өчен чистартылган чөгендернең ишле булуы да роль уйный. МСО, сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыклары, «40 лет Победы»да бу җәһәттән нәрсә уйлауларын һич аңламассың.

Заводның чөгендер кабул итү пунктында көндез машиналар бетеп тормаса да, башка еллардагыча «пик» сәгатьләре әллә ни күзәтелми әле. Әйтик, бракны ачыклаучы кызларга 6 октябрьдә көннең икенче яртысында яңгыр астында да әледән әле машиналар янына чыгарга туры килсә дә, икенче көнне шул ук вакытта машиналар берән - сәрән генә килгәли иде инде. (7 октябрьнең ахыр мәгълүматлары бу язма матбугатка бирелгәндә әзер түгел иде әле). Иртәнге сәгатьләрдә машиналар нигездә якын - тирә хуҗалыклардан гына килә. Ераграк урнашканнарыннан исә беренче машиналар төш чорында гына килеп җитә. Ә инде кичке алтылардан соң машиналар ташкыны бөтенләй азая һәм сигезләргә бөтенләй тукталып кала. Моны көннең кыскалыгы белән аңлатырга тырышучылар да бар. Әмма бит кайбер бик ерак хуҗалыклардан кичен төяп калдырылган чөгендерне булса да иртән иртәрәк китереп җиткерергә тиешләр ләбаса.

Китерелә торган чөгендернең сыйфаты турында да берничә сүз. 6 октябрьдә хуҗалыклардан барлыгы 2569 тонна йөк килгән, ә заводка чимал буларак кабул ителгәне 2157 тонна. Димәк ул көнне машиналар 411 тонна туфрак,башка төр артык йөк ташыганнар булып чыга. Ул көнне иң пычрак чөгендер Мичурин исемендәге хуҗалыкныкы булды - пычраклылык күрсәткече 21,4 процент. Иң чистасы - «Алга»ныкы иде - 12,2 процент. Гомумән алганда ул көнне Хафизов исемендәге хуҗалык машиналары 80 тонна,«Кондырча»лылар 40, «Киекле»ләдән 45, «Чирмешән»нән 33, шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгыннан 25 тонна балчык китерделәр булып чыга. Шулкадәр «йөк»не кырдан заводка озату өчен күпме ягулык ягылган, шоферларына хезмәт хакы язылган бит. Икенчедән, ашлаган - ниткән уңдырышлы җирнең күпме туфрагы шәһәргә күчерелә. Билгеле, болар - беръяклы гына, ягъни кабул итүче генә биргән мәгълүматлар. Шуңа күрә бу мәсьәләгә хуҗалыкларда да аз гына булса да игътибар бирелсә иде. Бу очракта чөгендернең һәм аны төяп озата торган машина әрҗәсенең ничек чистартылуына игътибар бирү турында гына сүз бармый, ә агрономнарга яки башка белгечләргә заводның чимал лабораториясендә ешрак булу зарурлыгын да кабатларга туры килә. Күпме кешенең хезмәте кергән чималны асылда аның өчен берниди җаваплылыгы да булмаган шофер кулына гына тапшырып тынычлану җиңел, билгеле. Әмма бит чөгендер тапшырып беткәннән соң саный - исәпли башлагач терсәкне тешләрдәй булырга мөмкин дә бит, тик эш үткән булачак.

**Ф.МИНГАЛИМОВ,**
**авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең чөгендерчелек буенча баш агрономы.**

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

# Укучыларыбыз хатлары

## Мәктәпләрдән язалар

### КҮҢЕЛ КЫҢГЫРАУЛАРЫ

*Чаларган чәчле өлкән педагогларыбыз килеп кергәч, мәктәп стеналары кабат җанланып киткәндәй булды. Ләкин сафлар инде сирәгәйгән. Әнә алар - Нурия Лотфулловна Яруллина, Наҗия Гайнулловна Зарипова, Госман Әхмәтович Ишмаев, ирле - хатынлы Миннегөл Әгъләмовна һәм Гомәр Шәймәрданович Вәлиевлар.*

*Кайчандыр алар да мәктәп тормышы белән янып яшәгән, нәкъ хәзерге шикелле көмеш чыңлы кыңгыраулар мәктәпкә чакырганнар һәм озатканнар. Бу дулкынландыргыч минутларда хәтта мәктәп директоры Вахит Касыймович Зәйнетдинов үзе дә каушады. Шулай булмый мөмкин дә түгел иде шул, кайчандыр бит ул үзе дә Нурия, Наҗия апаларның, Гомәр абыйларның укучысы булган.*

*Пенсионер - укытучылар үз укучыларын бүгенгедәй яхшы хәтерлиләр.*

*- Хәмзә мәктәпне тантаналы ачу көнендә, дулкынлануы сәбәпле лентаны кисә алмыйча азапланган иде, шунда кулларыннан тотып кистердем, - дип искә ала Наҗия Гайнулловна.*

*Бар да тын калалар. Бүгенге көндә инде ул юк. Хәмзә Садыйков билгесез рәвештә югалып ата - анасына, туганнарына әйтеп бетергесез кайгы китерде. Аны һәм бу дөньядан киткән укытучыларны хөрмәтләү йөзеннән мәктәпнең уку - укыту эшләре бүлеге мөдире Гадәния Миннәхмәтовна Сафиуллина бер минутлык тынлык белән искә алырга чакырды. Тантанада мәктәпнең элеккеге җыештыручылары Зөһрә Сибгатуллина, Фаизә Гыйләҗева, Һаҗәр Насыйбуллина, Мәдинә Кыямовалар да катнашты.*

*Мәктәп вожатые Румия Вахитовна Алиева. оештырган монтаж - концерт та пенсионер укытучыларның күңелләренә хуш килде.*

**Г.ФӘСХЕТДИНОВА.**
*Кәкре Атау.*

### БӘЙРӘМГӘ ЧАКЫРЫП ЧЫҢЛАДЫ КЫҢГЫРАУ

Быел район мәктәпләрендә укытучылар көнен яңача билгеләп үттеләр. Тантаналы җыелышлар 4 октябрь көнне кыңгырау чыңы буенча нәкъ 14.00 сәгатьтә башландылар. Аксумла урта мәктәбендә дә шулай булды. Авыл мәдәният йортына педагоглардан тыш ата - аналар, күрше мәктәпләрдән кунаклар, ветеран укытучылар да килгән иде.

Җыелышны директорның тәрбия эшләре буенча урынбасары Семенова Ирина Петровна ачты. Аның кыскача чыгышыннан соң укучылар һәм укытучылар тарафыннан әзерләнгән концерт булды, шунда ук укытучы - пенсионерларга тыйнак бүләкләр тапшырылды. Мактау кәгазе һәм акчалата премия белән чуваш теле укытучысы Г.М.Ендиряков бүләкләнде. Бу көнне Кормыш җирле үзидарә Советы рәисе М.И.Җәлалов, пенсионерка, Аксумла урта мәктәбенең элеккеге директоры В.И.Сибулатова, Илюткино урта мәктәбе укытучысы С.П.Семенова, Елаур урта мәктәбе укытучысы Л.Н.Парукова да педагогларны бәйрәм белән котладылар. Тантана бәйрәм өстәле артында тәмамланды.

**А.КОСТИН.**

### Олыларны олылап

Без, элеваторда эшләп, лаеклы ялга чыккан пенсионерлар өлкәннәр көнен көтеп алабыз. Җыелышып бергә үткәргән көннәрне искә алабыз, тормышыбыз, балаларыбыз - оныкларыбыз турында сөйләшәбез.

Шуңа шатланабыз: элеватор җитәкчелеге без ветераннарга һәрчак игътибарлы. Гадәти көннәрдә дә хөрмәтлиләр үзебезне. Бәйрәмнәрдә аеруча инде. Әле менә өлкәннәр көнендә Түбән Норлатка махсус автобус җибәртеп, пенсионерларны Норлатка алып килделәр. Сый - нигъмәт тулы өстәлләр артында рәхәтләнеп сөйләшеп, сыйланып утырдык. Шуңа да без элеватор администрациясенә, аеруча аның директоры, олыны олы, кечене кече итә торган олы җанлы кеше Ә.Н.Миназовка бик рәхмәтлебез.

**Р.ӘБҖӘППАРОВА.**
**Түбән Норлат авылы.**

## Бер бәйрәмгә - ике караш

### Җылы сүз ишетмәдек

Картлык - болай да авыр халәт. Гомер буе эшләп тә, картаймыш көнендә кешегә кирәксез калуың исә икеләтә уңайсыз. Бүген шул хәлдә мин. Йөрәгем елый, өзгәләнә. Кырык еллап бер ялсыз сыер саудым, иплән килеп чакырганда бүгенге көнгәчә туган хуҗалыгыма булышам.

Дөрес аңлагыз, мескенләнү түгел бу. Туганнарым, дусларым булганда игътибарга да, хөрмәткә дә тук мин. Сүзем икенче нәрсә турында: быел өлкәннәр көнендә безнең Әмзә җирле үзидарәсенә караган авылларда бер генә кешегә дә «Бәйрәм белән» дип әйтүче булмады. Билгеле инде, авыл җитәкчелеге турында әйтүем. Ярар, безнең мескен хуҗалыкның өлкәннәргә бүләк яисә чәй өстәле әзерләрлек рәте дә булмасын ди. Әмма иртәнге наряд вакытында җирле радио аркылы булса да өлкәннәр адресына әйтелгән берничә сүздән дә күңелебез булган булыр иде. Моңа бик мохтаҗ идек без. Чөнки арабызда кемнәр генә юк: сугышның башыннан азагына кадәр кан коеп сугышкан, ачлык - ялангачлыкны күргән, хәзер япа - ялгыз, авыру килеш тилмереп яшәп ятучы кешеләр һәм башкалар. Җылы сүзгә, сирәк кенә булса да аз гына игътибарга да бик сөенерләр, яшәүгә дәртләре үсеп киткән булыр иде, мөгаен.

Ә бит картлык һәркемгә дә килә. Бүген җир җимертеп, дөнья кендеге булып яшәүчеләргә дә килә ул. Өлкәннәрне хөрмәт итмәгәннәр үзләре дә булмас хөрмәтле - шуны онытмасыннар иде алар.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА,**
**хәбәрче.**
**Яңа Әмзә авылы.**

### Мостафин егетләре алар

«Татнефть - Норлатнефтеразведка» ОООсында мастер Җәмил Хәйдәрович Мостафин җитәкчелегендәге бригада яхшы исәптә йөри. Коллектив үзенә җиткерелгән планнарын айныкын айга уңышлы үтәп бара. Узган айда, мәсәлән, Мостафин егетләре Пионер нефть ятмасында 2.620 метр тау токымнарын бораулап, айлык планнарын 100 процентка үтәделәр.

Гомуми уңышка бораулаучылар Фаил Зәйнетдинов, Александр Гордеев, аларның ярдәмчеләре Илдус Баринов, Җәмил Әхмәтвәлиев, Илдар Яруллин һәм Нәбиулла Ишниязов аеруча зур өлеш керттеләр. Электрчы Владимир Александров, слесарь Сергей Малышев, шулай ук су белән тәэмин итү агрегаты машинистлары Фәргать Гыйззәтуллин һәм Рәис Гыйльмановның да тырыш хезмәтләрен югары бәялисе килә. Пешекче Татьяна Магинаның тәмле ашлары да егетләрне җитештерүчән хезмәткә рухландырып тора.

Мостафин егетләре еллык планны да вакытыннан элек үтәү өчен тырышалар бүген.

**Р.РӘХМӘТУЛЛИН,**
**хәбәрче.**

## Рәхим итегез: Сезне көтәләр...

-Кемнәрне ул, «Сезне»,дисезме?

-Урта белемегез бармы?-бар.Алга таба укып,һөнәр алырга телисезме?-Телисез.

Нәкъ менә шундыйларыгызны көтәләр дә инде.

-Кемнәр,кайда көтә соң безне,дисезме?

-Казанның үзендә көтәләр.Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты каршындагы баш архив идарәсендә һәм 9нчы һөнәри лицейда.

-Әһә, архивчылыкка укырга чакыралар икән, дисезме?

-Әлбәттә,хөкүмәтебезнең Архив идарәсе җыя икән инде, димәк, безгә шул һөнәргә күңеле яткан һәм махсус белем алган архив хезмәткәрләре кирәк.

Ә менә соңгы елларга кадәр бездә шул белгечләрне әзерләүче уку йорты юк иде.Нибары өч ел элек хөкүмәтебезнең Баш архив идарәсе Казандагы 9нчы һөнәри лицей нигезендә «Архивчыларның һәм идарә хезмәткәрләренең тоташтан белем алу үзәге» булдырылды.

Якынннанрак танышу өчен мин шул Үзәккә барып чыктым,шундагы мөгаллимнәргә сез бирәсе сорауларымны күндердем.Сезгә җавап бирәләр-9нчы лицейның директоры Биккенин Ренат Әхмәт улы һәм аның урынбасары Гобелко Александра Михайловна:

-Һөнәр училищелары да,лицейлар да,билгеле булганча,аз түгел. Безне башкалардан аерыбрак торган бер ягыбыз бар,без секретарь-референтлар әзерлибез.Идарә урынnарында эш-хезмәт кәгазьләре белән эш йөртә белергә,русча әйткәндә,»делопроизводство» һөнәренә өйрәтәбез.Шул үзенчәлегебезне күреп,мөмкинлекләребезне танып, Баш архив идарәсе җитәкчесе Дамир Рәүф улы Шәрәфетдинов әлеге белгечлегебезне киңәйтергә тәкъдим итте.Һәм бездә «делопроизводство, архивоведение» дигән белгечлек барлыкка китердек.

Өч төркем җыйган идек,берсе укуларны тәмамлады инде.Аларга «Эш-хезмәт документларын алып баручы, архивчы» белгечлеге белән урта-махсус белем алу турында Дәүләт Дипломы тапшырылды.

Белгечлектән аңлашылганча,безнең студентлар төрледән-төрле оешмаларның идарәләрендә,секретариатларында, канцелярияләренда,гомуми бүлекләрендә,кадрлар бүлекләрендә,ведомство архив хезмәтләрендә квалификацияле хезмәткәрләр була алалар.Алар һәркайда һәрчакта кирәкле белгечләр.

Укыту архив идарәсе, республика архивлары,Казан дәүләт университеты һәм лицей базасында алып барыла.Дәресләр аларның залларында,аудиторияләрендә үтә,практик өйрәнү-күнегүләр архив документлары белән алып барыла. Өйрәтүчеләребез-архив эше белгечләре,тарихчы галимнәр һәм лицей укытучылары.

Әйтеп куйыйк:лицейны тәмамлаган белгечләребез,теләк белдергән очракта,укуларын Казан университетының тарих факультетында дәвам иттерә алалар.Без аларны шунда кыскартылган укуга тәкъдим итә алабыз.

Быел үзебезгә укучыларны күршеләребездән-Идел-Урал арасындагы республикалардан,өлкәләрдән дә чакырабыз.Республикабызның район хакимиятләрендә безнең белешмәләр бар инде. Аларда күрсәтелгәнчә:

-укырга имтиханнарсыз кабул итәбез;

-уку срогы 2 ел;

-уку читтән торып алып барыла,студентлар һәркайсы 20 шәр көнлек кышкы һәм җәйге сессияләргә Казанга чакырыла.

-алар сессия чорында тулай торак белән тәэмин ителә.

Хәзер кабул итү комиссиясе эшли.Бездә укырга теләге булганнардан тиешле документларны көтеп калабыз.

Укулар октябрь уртасыннан башлана.

-Үзегез белән ничек бәйләнешкә керергә кирәклеген дә әйтегез инде?

-Менә алар:

-420111,Казан шәһәре,Кремль урамы, 2/6.

Баш архив идарәсе һәм

-420029,Казан,Халитов урамы,9.

9нчы һөнәри лицей.

Телефоннарыбызны да әйтәбез:38-49-87;75-48-09.

Булачак идарә хезмәткәрләре,кадрлар хезмәте белгечләре,архивчылар.Сезне белемнәрегезне арттырырга көтәләр.Рәхим итегез!

**Хәмзә ЗАРИПОВ,**
**архив хезмәткәре.**

# Беренче чара - җиңел атлетчыларныкы

Укытучылар көнендә җиңел атлетика буенча үткән район ярышлары балалар - яшүсмерләргә физик тәрбия бирү клубының (ДЮКФП) агымдагы уку елында үткәргән иң беренче массовый чарасы иде.

Әлеге ярышларда район мәктәпләреннән 11 команда җәмгысе 500ләп яшь спортчы килгән иде. Ул кызларның 1000 метрга йөгерүе белән башланып китте. Бу араны Вишневая Поляна мәктәбеннән Ивашковадан да тизрәк үтүче булмады. Макарова (Богдашкино) һәм Савельева (1 нче мәктәп) икенче һәм өченче урыннарны бүлештеләр.

1500 метрлы арада йөгерүдә дә Ивашковага тиңнәр табылмады. Каравыл Тавы авылыннан Фадеева икенче һәм Андреевка мәктәбеннән Порфирьева өченче булдылар.

Бу көнне егетләр арасында да иң оста йөгерүчеләрне билгеләдек без. Беренче мәктәптән Е.Яковлевның нәтиҗәләре аеруча шатландырды. Егет 1000 һәм 2000 метр арага узышканда да финишка беренче булып йөгереп килеп җитте. Шул ук мәктәптән В.Емелин исә анардан бик азга гына калышты. 1000 метрга йөгергәндә ул икенче, 2000 метрда өченче нәтиҗә күрсәтте. Призлы урын яулаучылар арасында Богдашкино мәктәбеннән Ә.Шәрипов һәм С.Цыганов кебек егетләр дә бар иде.

Гомумкоманда ярышлары нәтиҗәсендә беренче урынны лаеклы рәвештә Богдашкино урта мәктәбе, икенчене беренче мәктәп, өченче урынны Андреевка мәктәбе яшь җиңел атлетчылары яуладылар.

**Ә.НӘБИУЛЛИН.**

# Яхшы кешеләр бар ул

Ул көн минем һәм балаларымның гомерендә кара тамгалы көн булып калыр инде - быелның 30 августында безнең фатирыбыз янды һәм шул утны сүндергәндә сөекле ирем һәм балаларымның әтиләре янып үлде. Утыз көн буена без дусларыбызга, кеше почмагына сыенып көн иттек. Мин эшли торган Дәүләт санэпидкүзәтү үзәгендә баш табиб И.В.Әндаров һәм бухгалтер Н.В.Холина җитәчелегендәге хезмәттәшләрем безгә зур ярдәм, кешелеклелек һәм игелеклелек күрсәттеләр. Саэпидүзәкнең барлык хезмәткәрләренә, дусларыбызга һәм якыннарыбызга, күршеләребезгә, шулай ук иремне күмүне оештыруда булышкан, фатирыбызны ремонтлатуда катнашкан шикәр заводы, МСО, 547 нче ПМК, «Агрохимсервис» АҖ, Норлат геофизик эшләр идарәсе, УТТ, КСМ җитәкчелегенә, район үзәк шифаханәсе медицина хезмәткәрләренә, «Кыңгырау», «Ивушка», «Теремок» балалар комбинатларына ихлас рәхмәтебезне белдерәсебез килә.

Балаларыма шәһәрнең 3 нче мәктәбе укытучылары һәм класс җитәкчеләре, шулай ук укучылар да бик игътибарлы һәм ярдәмле булдылар. Безне бу авыр чакта ташламаган, кулларыннан килгән барлык ярдәмне күрсәткән һәркемгә тагын бер мәртәбә бик зур рәхмәт.

**Анфиса Калинина.**
**Норлат шәһәре.**

## ЭШКӘ ЧАКЫРАБЫЗ!

**Норлат район электр бүлү челтәренә эшкә кирәк:**

**- гамәлдәге 1000 вольттан югары электр линияләрендә эшләү өчен техник - электрик, подстанция начальнигына мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 2 - 14 - 55.**

**- Норлат подстанциясендә эшләү өчен югары яки урта техник белемле ОДГ диспетчеры.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Норлат шәһәрендә яшәүче кадерле әтиебез **Идрис Ислам улы Хәмәтвәлиевка** 9 октябрьдә 60 яшь тула.

Без аны туган көне белән чын күңелдән котлыйбыз. Аңа исәнлек - саулык, җан тынычлыгы, шатлыклы, кадерле картлык телибез.

Тарыйсың да чал чәчеңне сыйпап:
Картаелды инде, диясең.
Килә минем шул чал чәчләреңнең
һәрберсенә башым иясем.
Әткәй, әнкәй, сездән башка тагы
Кем бар шундый бала бәгырьле.
Кояш сыман әнкәй бирәү булса
Син дә безгә шулай кадерле.



**Сиңа изге теләкләр белән тормыш иптәшең, кызларың, кияүләрең, улың, оныкларың.**

*Кадерле әтиебез, тормыш иптәшем **Нәҗип Минһаҗетдин улы Җирҗизовка** 13 октябрьдә 60 яшь тула. Әти сине юбилееӊ белән чын күңелдән котлап, нык сәламәтлек, бәхет һәм әни белән тигез гомер кичерүеңне телибез.*

*Киләчәктә һәммәбезгә дә олы киңәшче булып, балаларыңның кадер-хөрмәтен күреп озак еллар яшәргә насыйп булсын.*

*Бүләгебез саф теләкләр*
*Сиңа әткәй, кабул итегез.*
*Изгелектә, игелектә,*
*Иминлектә гомер итегез.*

***Изге теләкләр белән әниебез, улларың, киленнәрең, кызың, киявең һәм 7 оныгың исеменнән олы улың Мөнип.***

Норлат шәһәрендә яшәүче кадерле әниебез, әбиебез **Миннегөл Касыйм кызы Газизованың** 10 октябрьдә туган көне.

Кешеләргә игътибарлы, ачык йөзле, мәрхәмәтле әниебез! Сине туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз. Сиңа озын гомер, гаилә бәхете, тыныч тормыш телибез.

Әни бит ул - өйнең яме,
Ә тормышта - олы бер терәк.
Озак яшә, әни, сәламәт бул
Син бит, әни, безгә бик кирәк.



**Иң изге теләкләр белән балалары исеменнән кызы Гөлнара, кияве Спартак, оныгы Диана.**

Хезмәттәшебез **Идрис Ислам улы Хәммәтвәлиевкә** 60 яшь. Аны олы юбилее белән кайнар котлыйбыз.

Күңелегез кителмәсен,
Олыгайган көнегездә дә
Бәхетегез кимемәсен
Ныклы сәламәтлек юлдаш булсын,
Эшегез һәрчак уң булсын,
Һәр яңа таң Сезгә бетмәс шатлык,
Тигез тормыш, кадер - хөрмәт китерсен.

**Изге теләкләр белән «Норлатнефть» - НГДУсы бухгалтериясе коллективы.**

*Кадерле сеңлебез **Гүзәл Әнвәр кызы Хаҗиморатованы** туган көне белән кайнар котлыйбыз.*

*Синең тормыш юлларыңда*
*Очрамасын киртәләр.*
*Гел шатлыклар, гел бәхетләр*
*Алып килсен иртәләр.*

***Иң изге теләкләр белән туганнары.***

## *Югары көчәнешле электр челтәрләрен саклау кагыйдәләре*

Бу кагыйдәләр югары көчәнешле электр челтәрләренең сакланышын тәэмин итү максатыннан кертелде.

1000 киловольттан югарырак көчәнешле һава электр үткәргеч линияләрнең нормаль хәлдә сакланышын тәэмин итү өчен:

- үткәргеч буенда ике яклап кырый чыбыклардан көчәнешенә карап 10 метрдан 30 метрга кадәр саклагыч зона калдырыла.

Саклагыч зоналарда тиешле электр челтәре предприятиеләре рөхсәтеннән башка:

- теләсә нинди корылмалар төзү, аларны капиталь ремонтлау яки сүтү;
- агачлар һәм куаклар утырту яки кисү, кыр станнары һәм көтүлекләр булдыру;
- юл өслегеннән гомуми биеклеге 4,5 метрдан артыграк булган машиналар һәм механизмнар йөртү Т Ы Е Л А.

Электр линияләренең нормаль эшләвен бозарга, аларга зыян ясар яки бәхетсезлек очракларына китерергә мөмкин булган эшләр башкару, аерым алганда:

- саклагыч зоналарда ягулык салу станцияләре урнаштыру;
- электр челтәре объектларына килү юлларын томалау;
- саклагыч зоналарда яки аларга якын урыннарда чүп ташлау урыннары булдыру;
- саклагыч зоналарда мал азыгы, салам, утын һәм башка материаллар өю, учак ягу шулай ук Т Ы Е Л А.

Югары вольтлы электр линияләрен саклау кагыйдәсе буенча хуҗалык территориясендә урнашкан югары көчәнешле линияләр корылмалары һәм трансформатор подстанцияләре сакланышы өчен җаваплылык әлеге хуҗалыклар җитәкчеләренә йөкләнә. Хуҗалык җитәкчеләре шулай ук бәла - каза килгәндә аварияне тиз арада бетерү өчен транспорт һәм кешеләр белән булышлык күрсәтергә тиешләр.

Электр линияләренең нормаль эш режимы бозылуны сизә калган очракта кичекмәстән постанциягә шалтыратуыгызны сорыйбыз. Тел.: 2 - 25 - 24.

**НРЭЭС администрациясе.**

# Белдерүләр

## САТАБЫЗ

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2101**. Адрес: Совет ур., 189 - 105.

***

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2101, кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 25 -27.

***

**ВАЗ - 21063.** Адрес: М.Җәлил ур., 8 - 1.

***

**1994 елгы ВАЗ - 2106**. Тел.: 5 - 38 - 34.

***

**«Урал» мотоциклы**. Адрес: Мәктәп ур7, 11 - 31.

***

**ВАЗ - 2106**. Тел.: 5 - 27 - 34.

***

**Кулланышта булган стенка.** Тел.: 5 - 22 - 67.

***

**1984 елгы ВАЗ - 2101 һәм зур булмаган йорт.** Адрес: Красин ур., 21.

***

**Запас частьләре белән ГАЗ - 21 автомашинасы**. Адрес: Куйбышев ур., 78а, 2 нче фатир, Хәлиуллиннар.

***

**1994 елгы чия төсендәге ВАЗ - 21213, 1992 елгы сафари төсендәге ВАЗ - 21043.** Тел.: 2 - 26 - 95.

***

**Төзелеш материаллары, блоклар, плитәләр, шифер.** Тел.: 5 - 14 - 36, 18 сәг.тән соң.

***

**Бишеге белән «ИЖ - ЮПИТЕР - 5» мотоциклы, 1 млн. сум.** Тел.: 2 - 13 - 58.

***

**ВАЗ - 2101**. Тел.: 2 - 11 - 50, 18 сәг.,тән соң.

***

**Гараж, тәрәзә блоклары, феленкалы ишекләр, «Ока»га резина.** Тел.: 5 - 23 - 60.

***

**Шикәр заводында 5 бүлмәле йорт. Газ белән ягыла, кайнар суы, ваннасы, санузелы, канализациясе, мунчасы, гаражы бар.** Тел.: 2 - 13 - 06, 18 сәг.,тән соң.

***

**Барлык материаллары белән 3,5 х 5,5 метрлы мунча бурасы**. Адрес: 40 лет Октября ур., 41 йорт.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Җир реформасы һәм җир ресурслары буенча комитет юридик һәм шәхси затларга милеккә хокук бирүче дәүләт актлары тарата**. Сораулар белән комитетка (Советская ур., 119 нчы йорт, 4 нче фатир, тел.: 2 - 13 - 67, 2 - 14 - 37) мөрәҗәгать итәргә.

***

**Ногъманов М.Г. исеменә документлар пакетын табучыны бүләк бәрабәренә түбәндәге адреска кайтарып бирүен сорыйбыз: 2 нче Дачная урамы, 12.**

***

**Ике бүлмәле фатир бер бүлмәлегә алыштырыла яки сатыла.** Адрес: Завод ур., 5 - 6.

## *Әзерлибез:*

**Суүткәргеч, канализация, ванналарны чит ил материаллары белән реставрацияләү.** Тел.: 2 - 26 - 12, 2 - 26 - 95.

***Ашыгыч фото салон лабораториясе сезне үзенә чакыра. Безнең салон Школьная урамындагы «Көнкүреш хезмәте» йортының беренче катында урнашкан. Теләсә нинди документка фотоларны - ак - кара фотоны 30 минут, төслесен - 2 сәгать эчендә ясап бирәбез. Сезнең теләсә нинди фототасмагызны ачыкландырабыз һәм теләсә нинди размердагы фотосурәтне ясыйбыз. Теләсә нинди фотосурәтне зурайтабыз яки күбәйтәбез.***

**«Стинол» суыткычлары, суыткыч техникасы өлкәсендә соңгы казанышларны туплаган, югары ышанычлылык һәм зур хезмәт итү срогына ия көнкүреш техникасы. Камилләштерелгән суыту системасы, ышанычлы җылылык изоляцияләү, «DANFOSS» (Голландия) һәм «MATSUSHITA» (Япония) фирмалары компрессорлары сезнең суыткычка иң яхшы эксплуатация сыйфатлары бирәләр. Норлат һәм район халкының күбесе моңа ышандылар инде.**

**«Индезит» кер юу машиналары һәм «Аристон» газ плитәләре - гомумән көнкүреш техникасы могҗизалары. Аларда кер юу һәм ризык әзерләү сезгә зур канәгатьләнү китерер, чөнки алар «тулы» автоматлар. Ышанычлылык, матурлык һәм уңайлылык - бу могҗизаларны чыгаручы «Мерлони» Италия фирмасының девизы шундый. Моннан тыш сез «Самсунг», «Сони», «Панасоник», «Шарп» һәм башка фирмаларда чыгарылган телевизорлар, аудио һәм видео аппаратуралар ала аласыз. Үзегезгә һәм сөекләләрегезгә бүләк ясарга онытмагыз. Гарантия һәм илтеп бирү гамәлдә. Безнең адрес: «Техника» кибете, икенче кат.** Лицензия номеры Б7 № 030770.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә. Заказ N 9186.